СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

28.10.2020 с.Ямбулатово 2 – 18

Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020нче елның 6нчы августындагы 658нче номерлы карары, Югары Ослан муниципаль районының Ямбулат авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Советының
2020нче елның 28нче октябреннән
2-18нче номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет сәркатибе | 15292 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Советының
2020нче елның 28нче октябреннән
2-18нче номерлы карарына
12нче кушымта

Ямбулат авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләре күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 15759 |

2. Әлеге карар 2020нче елның 1нче октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Советының Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы Н.В. Бугорков